ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«21» «октябрь» **2024 ел** **№** 766

**2025 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы балаларына туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларының һәм күппрофильле өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Татарстан Республикасы балаларына туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле өстәмә белем бирү учреждениеләрен һәм күппрофильле өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары, Арча муниципаль районы Уставы нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2025 елга түбәндәгеләрне кушымта нигезендә расларга:

Арча муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү оешмаларында һәм күппрофильле өстәмә белем бирүче оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны;

өстәмә белем бирү оешмаларында һәм күппрофильле өстәмә белем бирү оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтмә коэффициентны 0,75 күләмендә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны;

балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнарын гамәлдә булу чоры дәвамында балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карауны.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р. М. Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
21.10.2024 ел, №766
карары белән расланды

## Арча муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү оешмаларында һәм күппрофильле өстәмә белем бирүче оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм мәдәни юнәлешле өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программалары юнәлеше | Территория ягыннан урнашуы | Норматив чыгымнар, бер укучыга елга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Укуның беренче елы | Укуның икенче елы | Өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгати-эстетик | шәһәр җирлеге | 8280 | 15333 | 18399 |
| | авыл җирлеге | 8680 | 16074 | 19289 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 8179 | 15145 | 18174 |
| | авыл җирлеге | 8579 | 15887 | 19064 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 8583 | 15895 | 19074 |
| | авыл җирлеге | 8984 | 16636 | 19963 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 7976 | 14771 | 17725 |
| | авыл җирлеге | 8376 | 15512 | 18614 |
| Социаль-икътисади | шәһәр җирлеге | 7976 | 14771 | 17725 |
| | авыл җирлеге | 8376 | 15512 | 18614 |
| Табигый фәнни | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |